Питрәч районы методик кабинеты
Шәле урта гомуми белем бирү мәктәбе

“Иярченле кушма җөмләләр” 8 нче сыйныф өчен татар теленнән дәрес эшкәртмәсе

Укытучы: Хәсәнова Миңзифа Гыйльми кызы

Тема. Синтетик иярчен җөмләләр.

Максат. Синтетик иярчен җөмләләрне аера белергә өйрәтү.
Тыныш билгеләрен дөрес куярга күнектерү. Бәйләнешле сөйләмдә синтетик җөмләләр куллана алуга ирешү.

Җиһазлар. Дәреслек 8 нче сыйныф өчен, карточкалар, «Ромашка» уены, таблица.

1. Актуальләштерү.

1. Иярченле кушма җөмлә нинди җөмләләрдән тора?

Җавап. Иярченле кушма җөмлә: баш җөмләдән һәм иярчен җөмләдән тора. Баш җөмлә ияртә, ә иярчен җөмлә ияре.

2. иярчен җөмлә баш җөмләнең кайсы урынында килә? Ул, кушма җөмләнең ахырында торып, аны тәмамлый аламы?

Җавап. Иярчен җөмлә күп очракта баш җөмләнең алдыннан килә. Ә кайсы очракларда кушма җөмләнең ахырында торып, аны тәмамлап та килә ала.

3. Ә хәзер иярченле кушма җөмләләргә мисаллар китерегез.

Җавап. 1. Ул җыелышка килеп кергәндә, трибунада карчыга йөзле бер кеше сөйләп тора иде.

2. Хәйбулла кергәндә, сыер һәм сарыклар аяк өстендә сабырсызланып көтеп торалар.

3. Тагын шунысы кызык: Наил бер сүз дә әйтми иде. 4. Тик минә шунысы кыен: мине аяк ярасы белән госпитальгә җибәрделәр.

4. Дөрес, укучылар. Иярченле кушма җөмләләрне дөрес уйладыгыз. Ә минә кайсылары «Синтетик иярчен җөмләләр», кайсылары «Аналитик иярчен җөмләләр?»

Җавап. 1, 2 нче җөмләләр төзелешләре буенча, ягъни баш җөмләгә бәйләүче чараларның хәбәр составында торуына карап, иярчен җөмләләр синтетик булалар, ә 3, 4 нчеләр аналитик булалар.

2 Төп өлеш. Минә без бүген «Синтетик иярчен җөмләләр»не өйрәнәбез. Хәзер таблицага карагыз, җөмләләрне берәм-берәм яза барабыз.

Мисаллар	Схема һәм бәйләүче чаралар
1. Эшкә теләк булса, белек чыдар.	1. (... - са), ( )
2. Уйнап туктагач, Илсөяр өйгә йөгереп керде. (Г.Г-й)	2. (... - гач), ( ) Кушымчалар.

Изм.	Лист	№ докум.	Подп.	Дата	Лист

Подп. и дата · Инв. № дубл. · Взам. инв. № · Подп. и дата · Инв. № подл.

3. Кырдагы печәнгә, бик көчле буран булганга күрә, бүген бер генә мәртәбә баралар.	3. (... (... - га күрә), ...)
4. Кар бетү белән, җир астыннан умырзая калкып чыга. 5. Яңгыр яуган булуга карамастан, юлда тузан басылмаган.	4. (... -у белән), ( ) 5. (... га карамастан), ( ) Бәйлек һәм бәйлек сүзләр.
6. Җире аз кешеләр батракка яллана иделәр. (Г.Б.)	6. ( ). ( ). Ике җөмлә арасында пауза юк - - янәшә тору чарасы.

1. Укучылар, без үткән дәрестә иярченле кушма җөмләләрнең иярчен һәм башка җөмләләрдән торуын, иярчен җөмләнең (һәм гомумән иярченле кушма җөмләнең) синтетик та, аналитик та була алуын белдек. Хәзер синтетик җөмләләрне җентекләп өйрәнә башлыйбыз.

Беренче җөмләне укытучы ярдәме белән бер укучы анализлый һәм нәтиҗә чыгара. Башта андагы ике җөмлә аерып күрсәтелә, кайсы – баш, кайсы иярчен җөмлә булуы әйттерелә. Бу өлешен укытучы йомгаклап куя:

Синтетик иярченле кушма җөмләләрдә аерым тора торган гади җөмләгә охшаган җөмлә баш җөмлә була. Бу җөмләдә баш җөмлә кайсысы?

Җавап. Беләк чыдар, чөнки моны аерым тора торган гади җөмләгә охшатып әйтеп була, аның хәбәре гади җөмлә хәбәре кебек тулы формалы: чыдар.

2. Синтетик иярченле кушма җөмләләрдә аерым тора торган гади җөмләләргә охшамаган җөмлә синтетик иярчен җөмлә була. Бу җөмләдә синтетик иярчен җөмлә - эшкә теләк булса, чөнки аны, аерым тора торган гади җөмлә кебек итеп, үзен генә аерым әйтеп булмый, алай әйтсәң, фикер тәмамланмыйча кала, аның хәбәре дә гади җөмлә хәбәренә охшамаган, ягъни тулы формалы түгел.

3. Укучылар, тора торган гади җөмләгә охшатып әйтеп була, аның хәбәре гади җөмлә кебек тулы формалы: чыдар.

2. Синтетик иярченле кушма җөмләләрдә аерым тора торган гади җөмләләргә охшамаган җөмлә синтетик иярчен җөмлә була. Бу җөмләдә синтетик иярчен җөмлә -- эшкә теләк булса, чөнки аны, аерым тора торган гади җөмлә кебек итеп, үзен генә аерып әйтеп

Подп. и дата
Инв. № дубл.
Взам. инв. №
Подп. и дата
Инв. № подл.
Изм. Лист № докум. Подп. Дата
Лист

булмый, алай әйтсәң, фикер тәмамланмыйча кала, аның хәбәре дә гади җөмлә хәбәренә охшамаган, ягъни тулы формалы түгел.

3. Укучылар, эшкә теләк булса җөмләсе тулы формалы булсын дисәң, аны ничек үзгәртеп булыр иде?

-- Әйе, эшкә теләк булды (бар). Эшкә теләк бар (була). Эшкә теләк булачак формаларында үзгәртеп булыр иде.

4. Ни өчен ул менә шулай гади җөмләгә охшап килмәгән?

-- Дөрес, чөнки ул иярчен җөмлә баш җөмләгә бәйләнеп килү өчен, --са кушымчасын алган.

5. Димәк, синтетик иярчен җөмләне баш җөмләгә бәйләүче чара кайсы кисәк эчендә килә?

-- Әйе. Бу җөмләдә бәйләүче чара – са иярчен җөмләнең хәбәре составында килә, шуңа күрә иярчен җөмлә аерым торган гади җөмләгә охшамый, баш җөмләгә керешеп китә, ягъни баш җөмлә синтезлаша һәм синтетик иярчен җөмлә дип атала.

6. Хәзер әйтегез әле: синтетик иярчен җөмлә, җөмлә ахырында килеп, аны тәмамлап куя аламы? Ягъни бу җөмләне әдәби телдә Беләк чыдар, эшкә теләк булса дип язып буламы?

-- Дөрес, алай язып булмый, телдән сөйләгәндә һәм шигъри әсәрләрдә генә андый тәртип очрарга мөмкин. Димәк, синтетик иярчен җөмлә, хәбәре тулы формалы булмаганлыктан, гадәти язма сөйләмдә кушма җөмләнең ахырында килеп, аны тәмамлап куя алмый.

7. Баш җөмләгә кушымчалар аша бәйләнгән синтетик иярчен җөмләләрнең башкаларын да шул юл белән анализлап була. Укучылар әйбәт төшенсәләр башка җөмләләрне анализлауга вакытны бик аз гына бирергә була. Ягъни ул җөмләләрне аерым-аерым түгел, бөтенесен берьюлы анализларга мөмкин.

8. Баш җөмләгә бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр белән ияргән синтетик иярчен җөмләләрне анализлау да шул ук сораулар белән, шул ук тәртиптә алып барыла. Ләкин биредә синтетик бәйләүче чараларның үзенчәлегенә игътибарны ныграк юнәлдерергә кирәк.

9. Укучылар, игътибар итегез әле, бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр, синтетик чара буларак, кушымчалардан нәрсә белән аерыла икән?

Дөрес. Кушымчалар иярчен җөмләнең хәбәренә кушылып язылалар, ә бәйлє һәм бәйлек сүзләр иярчен җөмлә хәбәренә кушылмыйча язылалар.

Изм.	Лист	№ докум.	Подп.	Дата		Лист

Подп. и дата | Инв. № дубл. | Взам. инв. № | Подп. и дата | Инв. № подл.

-- Ләкин аңа карап, бәйлек һәм бәйлек сүзләрне хәбәр составында тормый дип әйтеп буламы?

-- Юк әйтеп булмый. Ни өчен? Игътибар итегез: бәйлек һәм бәйлек сүзләр хәбәргә кушылып язылмасалар да, хәбәрнең формасын үзгәртәләрме? Мәсәлән, Кар бетү белән җөмләсе, белән бәйлеге хәбәр янында килмәсә һәм ул җөмләне аерым гади җөмлә итәргә кирәк булса, ничек әйтелер иде?

-- Дөрес. Кар бетте формасында булыр иде. Димәк, бәйлек һәм бәйлек сүзләр иярчен җөмләнең хәбәренә кушылып язылмасалар да, хәбәрнең тулылыгын юкка чыгаралар, хәбәр формасын тәшкил итәләр, шуңа күрә алар, кушымчалар кебек үк, синтетик иярчен җөмләләрне төзүдә катнашучы чараларга керәләр.

10. Җире аз кешеләр батраклыкка яллана иделәр җөмләсен анализлау иярчен җөмләне һәм баш җөмләдә аны ияртүче сүзне тапшырудан башлана: җире аз иярчен җөмлә, кешеләр – иярчен җөмләне ияртеп, буйсындырып килә торган сүз.

-- Хәзер җире аз дигән иярчен җөмләне аерым гади җөмлә кебек әйтеп карагыз. Әйтеп буламы? Аның хәбәре составында бәйләүче чара бармы?

-- Әйе. Бу төр иярчен җөмләне, мөстәкыйль торган гади җөмлә кебек, аерып әйтеп була. Хәбәре составында бәйләүче чара да юк. Алай булгач, ул баш җөмләгә нинди чара ярдәмендә бәйләнә соң? Игътибар итегез әле: җире аз иярчен җөмләсеннән соң пауза ясап әйтеп буламы? (Укытучы ясап әйтеп күрсәтә).

-- Димәк, җире аз иярчен җөмләсе баш җөмләдән пауза белән аерылып тормый, ияртүче сүз белән янәшә килә һәм бәйләүче чара – янәшә тору чарасы. Менә шуларны истә тотып, мондый җөмләләрне (хәбәре составында бәйләүче чара булмаса да, җөмлә гади җөмләгә охшаган булса да) синтетик җөмләләргә керәләр.

Синтетик иярчен җөмләләр татар теленең (һәм төрки телләренең) үзенчәлеге булып тора. Алар, мәсәлән, рус телендә юк.

3. Күнекмәләрне ныгыту.

1. Билетларда бирелгән гади җөмләләр белән синтетик иярченле кушма җөмләләр төзеп язарга. Ничә төрле итеп төзер идең?

4. 2. Телдән 64 нче күнегүне эшләргә. (57 нче күнегү). Синтетик иярчен җөмләләрне табып әйтергә.

Подп. и дата
Инв. № дубл.
Взам. инв. №
Подп. и дата
Инв. № подл.

Изм.	Лист	№ докум.	Подп.	Дата	Лист

3. Иҗади диктант.

Спорт белән шөгыльләнә. Сәламәт була. Саф һавада йөри. Сулыш алуы рәхәт. Дәрес бетте. Чаңгыларны алып тауга китте. Азат көн саен саф һава сулый. Ул таза, сәламәт. Сәламәт кеше – тормышның яме.

а) Синтетик иярченле кушма җөмләләр дә кулланып иҗади эш итеп язарга.

5. «Ромашка» уены.

Бирем. Ромашканың һәр таҗын аерым укучы өзеп ала, алдагы ягын ачып җөмләләрне укыйлар, төре ягыннан нинди җөмлә икәнен әйтеп барырга.



2. Укучылар, бу уенны да дөрес башкардыгыз. Хәзер инде йомгак ясыйк. Синтетик иярчен җөмлә дип нинди җөмләгә әйтәбез, алар янында нинди тыныш билгеләре куела?

3. Дөрес. Без бүген синтетик иярчен җөмләләрне үттек. Әйбәт катнашуыгыз өчен рәхмәт.

6. Йомгаклау.

1. Билгеләр кую.

2. Өй эше. Синтетик иярчен җөмләләр дә кулланып «Кыш» дигән темага миниатюр сочинение язарга.

Кулланылган әдәбият.

1. М. З. Зәкиев. Татар теле 8 нче класс.
   Казан, “Мәгариф” нәшрияты. 1997.
2. В. Хаков “Татар теле стилистикасы”
   /күнегүләр өчен кулланма/
   Казан, Татарстан китап нәшрияты.
   1980 /60, 72, 97 нче битләр/
3. Н. В. Максимов, С. М. Трофимова, М. З. Хәмидуллина.
   Татар теленнән диктантлар һәм изложенияләр җыентыгы.
   Казан, “Мәгариф” нәшрияты. 1998.
4. Н. В. Максимов, С. М. Трофимова, М. З. Хәмидуллина.
   “Татар теленнән дидәктик материаллар”
   Казан, “Мәгариф” нәшрияты. 1997.

Мәгънәсеннән һәм бәйләүче чараларыннан чыгып, хәлләрне 8 төргә бүлеп йөртәләр: вакыт, урын, сәбәп, максат, рәвеш, күләм, кире, шарт хәлләре.

Урын хәле	Эш-хәлнең урынын күрсәтеп, фигыльгә буйсынып килгән хәл. Сораулары: кайда? кая? кайдан? (***Болында** матур чәчәкләр үсә.*)
Вакыт хәле	Эш-хәлнең вакытын белдереп, фигыльне ачыклап килә. Сораулары: кайчан? кайчанга чаклы? кайчаннан бирле? (***Кичә** кызыклы фильм карадык.*)
Рәвеш хәле	Эш-хәрәкәтнең ничек үтәлүен белдереп килә. Сораулары: ничек? ни рәвешле? Синтаксик чаралар: хәл фигыль формасы, ***-дай, -дәй, -ча, -чә*** кушымчалары, бәйлек һәм бәйлек сүзләр. (*Кызның ике бите **уттай** яна иде.*)
Күләм хәле	Билгенең дәрәҗәсен белдерә һәм сыйфат белән рәвешкә буйсынып килә. Сораулары: күпме? күпмегә? күпмедән? никадәр? ничә тапкыр? ни дәрәҗәдә? (*Белгечләр **озак** тартыштылар.*)
Сәбәп хәле	Эш-хәрәкәтнең сәбәбен белдереп, фигыльгә буйсынып килә. Сораулары: ник? нигә? нилектән? ни сәбәпле? ни (нәрсә) аркасында? ни өчен? (***Шатлыгыннан** аның күзләре очкынланып китте.*)
Максат хәле	Эш-хәрәкәтнең нинди ният белән үтәләчәген күрсәтә. Сораулары: ни өчен? нигә? нинди максат белән? ***Өчен*** бәйлеге, ***дип, максатыннан, ниятеннән*** сүзләре белән фигыльгә иярә. (*Егет шәһәргә **укырга дип** килде.*)
Шарт хәле	Эш яки хәлнең шартын белдереп, фигыльгә буйсынып килә. Сораулары: нишләсә? нинди шартта? (***Теләсәләр**—барсыннар.*)
Кире хәл	Көтелгән эш-хәрәкәтнең киресен белдереп, фигыльгә буйсынып килә. Сораулары: нишләсә дә? нәрсәгә карамастан? (***Чакырса да**—бармады.*)